ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 декабря 2019г. № 6585

«2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген күтәрү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы карары белән расланган «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» федераль максатчан программасын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указын, Яр Чаллы шәһәре Уставының 41 статьясын, Башкарма комитетның 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары белән расланган Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен тормышка ашыру максатында

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 18 декабрендәге
6585 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2020-2022 елларга
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» муниципаль программасының
паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | 1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» федераль максатчан программасы турында» 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы карары;<br>2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы боерыгы;<br>3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы;<br>4. «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>5. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>6. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>7. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары. |
| Программаны эшләүче | Шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |

<table>
<tr><td>Программаны башкаручылар</td><td>- Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе<br>- Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br>- Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе (килешү буенча)<br>- Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе<br>- Башкарма комитетның финанс идарәсе</td></tr>
<tr><td>Программаның максатлары</td><td>1) ЮТҺ нәтиҗәсендә һәлак булучылар, шул исәптән балалар санын 9 кешегә кадәр киметү;<br>2) Җәмәгать пассажир транспорты катнашында ЮТҺне 30 га кадәр киметү;<br>3) Урам-юл челтәренең (алга таба – УЮЧ) норматив техник торышын ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>1) Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;<br>2) Машина йөртү культурасын арттыру;<br>3) Урам-юл челтәренең норматив техник торышын саклап тоту;<br>4) ЮТҺ концентрациясе урыннарын бетерү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>Программа 2020, 2021, 2022 елларга исәпләнгән</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="3">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2021</td><td>2022</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>316 064,01 мең сум</td><td>316 064,01 мең сум</td><td>316 064,01 мең сум</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td>Узган елның аналогик чоры белән чагыштырганда, 2020-2022 еллар азагына юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар санын 10% ка, зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре санын 30% ка киметү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруга контроль</td><td>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге
## һәм аны программа ысулы белән хәл итү зарурлыгын нигезләү

2019 елның 6 аенда Яр Чаллы шәһәре территориясендә зыян күрүчеләр белән 229 юл-транспорт һәлакәте булган, анда 4 кеше һәлак булган һәм 280 төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Узган елның аналогик чоры (алга таба – УЕАЧ) белән чагыштырганда юл-транспорт һәлакәтләре (алга таба – ЮТҺ) саны 28 фактка кимегән, юл-транспорт һәлакәтендә һәлак булучылар саны 2 кешегә, җәрәхәтләнүчеләр саны 21 кешегә кимегән.

Зыян күрүчеләр белән ЮТҺ санының, аларның килеп чыгу сәбәпләре буенча бүленеше түбәндәгечә:

- маневрлау кагыйдәләрен бозу (күчү, транспорт чараларының урнашуы, ян як интервал, дистанция, артка таба бару) нәтиҗәсендә 64 ЮТҺ булган, аларда 78 кеше җәрәхәтләнгән;
- җәяүлеләр кичүе кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә 34 ЮТҺ булган, аларда 1 кеше һәлак булган һәм 36 кеше җәрәхәтләнгән;
- юллар чатында йөрү кагыйдәләрен бозу (юл йөрү чираты, әйләнеш хәрәкәте, светофор) нәтиҗәсендә 55 ЮТҺ булган, аларда 1 кеше һәлак булган, 85 кеше җәрәхәтләнгән;
- билгеләнгән хәрәкәт тизлеген арттыру нәтиҗәсендә 36 ЮТҺ булган, аларда 46 кеше җәрәхәтләнгән;
- җәяүлеләр тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә 33 ЮТҺ булган, аларда 2 кеше һәлак булган һәм 32 кеше җәрәхәтләнгән.
- алкоголь кулланган хәлдәге җәяүлеләр гаебе белән 13 ЮТҺ теркәлгән, аларда 13 кеше җәрәхәтләнгән.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның имгәнүенә китергән аварияләрнең төп төрләре булып түбәндәгеләр тора:

- җәяүлеләрне таптату, 100 ЮТҺ булган, аларда кеше үлгән 3 һәм 102 кеше җәрәхәтләнгән;
- транспорт чаралары бәрелешү, 99 ЮТҺ булган, аларда 1 кеше һәлак булган һәм 143 кеше җәрәхәтләнгән.
- киртәләргә бәрелү, 8 ЮТҺ булган, аларда 10 кеше җәрәхәтләнгән.

2019 елның агымдагы чорында шәһәр территориясендә канәгатьләнмәслек юл шартлары нәтиҗәсендә 117 ЮТҺ булган (УЕАЧ – 146), шул вакытта 3 кеше һәлак булган (УЕАЧ - 3) һәм 146 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ – 162), бу ЮТҺнең гомуми санының 51% ын тәшкил итә (УЕАЧ – 56,2%).

Төп сәбәпләр булып түбәндәгеләр тора:

- горизонталь юл билгеләре булмау яки начар күренү – 68 ЮТҺ (УЕАЧ – 115);
- кышкы карап тотуда җитешсезлекләр – 43 ЮТҺ (УЕАЧ – 34);
- кирәкле юл билгеләре булмау – 15 ЮТҺ (УЕАЧ – 22);
- кирәкле урыннарда җәяүлеләр киртәләре булмау – 4 (УЕАЧ – 18).

Ачыкланган бозулар бүленеше түбәндәгечә:

- Аек булмаган хәлдә транспорт чарасы (алга таба – ТЧ) белән идарә итү - 674 факт.

Шул ук вакытта аек булмаган машина йөртүчеләр гаебе белән 17 ЮТҺ теркәлгән, аларда 26 кеше җәрәхәтләнгән.

2019 елда исерек хәлдәге машина йөртүчеләр катнашында матди зыян китергән 84 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән.

- Светофорның тыелган сигналына чыгу – 1637 факт, шул ук вакытта светофорның тыелган сигналына чыгучы машина йөртүчеләр гаебе белән 21 ЮТҺ теркәлгән;

- ТЧ белән машина йөртү таныклыгыннан башка идарә итү – 370, шул ук вакытта транспорт чаралары белән идарә итү хокукы булмаган яки мондый хокуктан мәхрүм ителгән машина йөртүчеләр гаебе белән 8 ЮТҺ теркәлгән;

- ТЧ белән куркынычсызлык каешларын эләктермәгән килеш идарә итү – 3751, шул ук вакытта куркынычсызлык каешын эләктермәгән килеш ТЧ белән идарә итүче машина йөртүчеләр гаебе белән 9 ЮТҺ булган.

- Балаларны махсус утыргычлардан башка йөртү – 431, машина йөртүчеләр гаебе белән 1 ЮТҺ теркәлгән.

ЮТҺ концентрациясе урыннарының топографик анализыннан күренгәнчә, 16 урын һәм ЮТҺ концентрациясенең потенциаль куркыныч 11 урыны исәптә кала. Концентрация урыннарында 114 ЮТҺ булган, нәтиҗәдә 3 кеше һәлак булган һәм 152 кеше төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган.

6 айда шәһәр территориясендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт катнашында 13 ЮТҺ булган, аларда 15 кеше җәрәхәтләр алган (УЕАЧ – 20-0-33).

Пассажирлар йөртүгә контрольне гамәлгә ашырганда автобус йөртүчеләр тарафыннан юл-транспорт кагыйдәләрен бозуның 2666 очрагы ачыкланган. Шуның:

- техник төзек булмаган транспорт чарасы белән идарә итү – 1965;
- билгеләнгән хәрәкәт тизлеген арттыру – 20;
- пассажирлар йөртү кагыйдәләрен бозу – 93;
- техник карау үткәрелмәгән килеш – 16.

Вазыйфаи һәм юридик затлардан 96 кеше административ җаваплылыкка тартылган.

## Балалар юл-транспорт травматизмы

2019 елның 6 аенда Яр Чаллы шәһәре юлларында 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 39 ЮТҺ булган, аларда һәлак булучылар юк, 43 бала төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган (УЕАЧ - 40).

ЮТҺдә зыян күргән балалар категориясе буенча бүлгәндә, УЕАЧ белән чагыштырганда үсешне күрсәткән түбәндәге картина күзәтелә: пассажир балалар катнашында – 9 (УЕАЧ – 6), велосипедчылар катнашында – 4 (УЕАЧ – 2), җәяүле балалар катнашында 26 ЮТҺ булган (УЕАЧ – 27).

2019 елның 6 аенда балигъ булмаганнарның саксызлыгы нәтиҗәсендә 12 ЮТҺ булган.

Шул факт борчу тудыра, балигъ булмаганнарның саксызлыгы нәтиҗәсендәге ЮТҺнең 10 сы башлангыч сыйныф укучылары һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре балалары катнашында булган. Бу – юлларда юл иминлеге тәртибе күнекмәләре әле аз формалашкан балалар категориясе. Андый яшьтәге балалар мөстәкыйль рәвештә юл хәрәкәтендә катнашуга әзер түгел әле.

Шулай итеп, программаны эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгы түбәндәге сәбәпләргә бәйле:

- проблеманың социаль-икътисадый кискенлеге;
- теләсә нинди юл ситуациясендә иминлек тәртибе күнекмәләрен булдыру;
- муниципаль берәмлек оешмаларында юлларда иминлек тәртибенә өйрәтә торган системаны камилләштерү өчен шартлар тудыру зарурлыгы;
- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын һәм җәмәгать институтларын проблеманы хәл итүгә җәлеп итү зарурлыгы.

Федераль һәм республика дәрәҗәсендә дәүләт ярдәме Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеге проблемасын нәтиҗәлерәк хәл итәргә мөмкинлек бирә.

3 бүлек. Программа чаралары.

Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау.

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручы лар | Төп чаралар ны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганагы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | База 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 |
| ЮТҺ нәтиҗәсендә һәлак булучылар ның, шул исәптән балалар санын кимету | Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы ясау системасы булдыру | «Яшь Хәрәкәт Инспекторы» кысаларында гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары белән «Куркынычсыз тәгәрмәч» акциясе | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | Агым дагы елның мае | Катнашкан укучылар саны | 260 | 270 | 270 | 270 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен «Игътибар - балалар!», «Игътибар - җәяүле!», акцияләре | | Агым дагы елның сентябре | Гомуми белем бирү учреждени еләренең гомуми күләмендә катнашкан укучылар өлеше % | 94 | 95 | 95 | 95 | Чара оештыру характерына ия | | |

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганагы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | База 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 |
| | | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны куркынычсыз юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү буенча «Куркынычсыз юл» дидактик уеннар зональ конкурсы | | Агымдагы елның гыйнвары | Үткәрелгән чаралар саны, данә | 8 | 8 | 8 | 8 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә Юл хәрәкәте иминлеге темасына лекцияләр | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМИ ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча) | Уку елы дәвамында | Үткәрелгән чаралар саны, данә | 65 | 65 | 65 | 65 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча материалларны яктырту | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Даими | Урнаштырылган материал саны, данә | 12 | 12 | 12 | 12 | Чара оештыру характерына ия | | |

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганагы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | База 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 |
| Җәмәгать пассажирлар транспорты ЮТҺ кимету | Машина йөртү культурасын арттыру | «Хаким Кубогы»на магистраль автопоездлар йөртүчеләрнең һөнәри осталык бөтенроссия конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Татарстанның логистика ассоциациясе (килешү буенча) | Агымдагы елның августы | Катнашучылар саны, кеше | 30 | 30 | 33 | 36 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Җәмәгать транспорты йөртүчеләрнең һөнәри осталык шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, «Пассажирлар йөртү» ЖЧҖ (килешү буенча) | Агымдагы елның июле | Катнашучылар саны, кеше | 20 | 20 | 22 | 25 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Җәмәгать транспорты йөртүчеләр белән стресс тотрыклылыгы һәм клиент ориентлашуы буенча курслар | | Квартал саен | Үткәрелгән лекцияләр саны, данә | 4 | 4 | 4 | 4 | Чара оештыру характерына ия | | |

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганагы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | База 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 |
| УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту | УЮЧнең норматив техник халәтен саклап тоту | Юллар, күперләр һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Агымдагы елның апреле – ноябре | Карап тотудагы кимчелекләр буенча ЮХИДИ күрсәтмәләренең саны | 270 | 256 | 243 | 231 | Шәһәр бюджеты 316 064, 01 мең сум | Шәһәр бюджеты 316 064, 01 мең сум | Шәһәр бюджеты 316 064, 01 мең сум |
| | | Юлларны кышкөне карап тоту | | Агымдагы елның декабре-марты | Карап тотудагы кимчелекләр буенча ЮХИДИ күрсәтмәләренең саны | 40 | 36 | 32 | 29 | | | |
| | | Юл билгеләре урнаштыру | | Агымдагы елның мае - октябре | ЮХИДИ күрсәтмәсе буенча урнаштырылган юл билгеләренең өлеше % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | Юл билгеләре төшерү | | Агымдагы елның мае - августы | Юл билгеләре төшерелгән автомобиль юллары өлеше, % | 90 | 95 | 100 | 100 | | | |

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручы лар | Төп чаралар ны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганагы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | База 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 |
| | | Светофор объектлары | | Агым дагы елның мае – октябре | ЮХИДИ күрсәтмәсе буенча урнашты рылган светофор объектлары ның өлеше % | 100 | 100 | 100 | 100 | 1 нче кушымта | 1 нче кушымта | 1 нче кушымта |
| | ЮТҺ концентрациясе урыннарын бетерү | ЮТҺ концентрациясе урыннарын бетерү (1 нче кушымта) | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Агым дагы елның апреле – ноябре | Бетереләә торган ЮТҺ концентрац иясе урыннарын ың саны | 16 | 16 | 13 | 10 | | | |

«ЮТҺ концентрациясе урыннарын бетерү»
1 нче кушымта

| Т/с | ЮТҺ КУ адресы | ЮТҺ төрләре | Аварияләрне киметү буенча тәкъдим ителә торган чаралар | Финанслау чыганаклары/ программа |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Машиностроительная урамы – Вахитов проспекты (Вахитов бoжрасы) | 5- бәрелешү<br>2 – җәяүлене таптату<br>1 – киртәгә бәрелү | 1.ПСП бoжра хәрәкәтенә кадәр озынайту.<br>2.Горизонталь юл билгеләре төшерү схемасын үзгәртү. | Җирле бюджет (финанслау булганда) |
| 2. | Тынычлык проспекты – Яшьлек проспекты | 2 – җәяүлене таптату<br>4 – бәрелешү | 1. «Фотовидеофиксация» 8.23 табличкасы белән «Максималь тизлекне чикләү – 40 км/с» 3.24 юл билгеләре урнаштыру.<br>2.Тавыш полосалары урнаштыру.<br>3.«Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру<br>4.«Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | п. 1-3 «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» федераль программа кысаларында<br>п. 4 – «ЮХК» ДБУ |
| 3. | Тынычлык проспекты – Рәис Беляев проспекты | 2 – җәяүлене таптату<br>4 – бәрелешү | 1.Рәшәткәле киртәләр урнаштыру.<br>2.«Җәяүлеләр кичүе» 5.19.1 кабатлау билгеләре урнаштыру.<br>3.Светофорның эш режимын үзгәртү («уңга борылу» секциясен алырга).<br>4.Җәяүлеләр өчен «Сулга кара» кисәтү юл билгесен төшерү.<br>5.«Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | п. 1-4 «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» федераль программа кысаларында<br>п. 5 – «ЮХК» ДБУ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Мәскәү проспекты – Халыклар дуслыгы проспекты | 2 – җәяүлене таптату<br>4 – бәрелешү | 1. «Җәяүлеләр кичүе» 5.19.1 кабатлау билгеләре урнаштыру – 2 данә.<br>2. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>3. «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>4. «Фотовидеофиксация» 8.23 табличкасы белән «Максималь тизлекне чикләү – 40 км/с» 3.24 юл билгеләре урнаштыру.<br>5. «Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | п. 1-4 Җирле бюджет<br>п. 5 – «ЮХК» ДБУ |
| 5. | Яр Чаллы проспекты – Нариманов урамы | 4 – бәрелешү<br>1 – әйләнеп каплану | 1. Җәяүлеләр кичүләрен үзгәртеп төзү.<br>2. «Җәяүлеләр кичүе» 5.19.1 кабатлау билгеләре урнаштыру.<br>3. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>4. «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>5. «Максималь тизлекне чикләү – 40 км/с» 3.24 юл билгеләре урнаштыру.<br>6. «Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | п. 1-5 «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» федераль программа кысаларында<br>п. 6 – «ЮХК» ДБУ |
| 6. | Сөембикә проспекты – Халыклар дуслыгы проспекты | 3 – бәрелешү<br>2 – җәяүлене таптату | 1.«Тукталышсыз хәрәкәт итү тыелган» 2.5 билгеләре урнаштыру.<br>2.«ЮТҺ концентрациясе урынына якынлашу» мәгълүмат такталары урнаштыру.<br>3.Чатны реконструкцияләүне проектлаштыру. | Җирле бюджет (финанслау булганда) |
| 7. | Сөембикә проспекты – Рәис Беляев проспекты | 1 – велосипедчыны таптату<br>4 – бәрелешү | 1. Рәшәткәле типтагы җәяүлеләр киртәләре урнаштыру.<br>2. «Җәяүлеләр кичүе» 5.19.1 кабатлау билгеләре урнаштыру» - 4 данә.<br>3. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>4. Светофорның эш режимын үзгәртү («Уңга борылу» секциясен демонтажлау). | Җирле бюджет (финанслау булганда) |
| 8. | Машиностроительная урамы – «Беркут» базасы | 3 – җәяүлене таптату | 1.Тавыш полосалары урнаштыру.<br>2. «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>3. Машиналар йөри торган юл алдындагы кичүгә килү юлларын өстәмә яктырту. | Җирле бюджет (финанслау булганда) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Трубный тыкрыгы – Индустриальный тыкрыгы | 3 – бәрелешү | 1.Светофор объекты кертү. | «ЮХК» ДБУ |
| 10. | Тынычлык проспекты – Халыклар Дуслыгы проспекты | 4 – җәяүлене таптату<br>6 – бәрелешү<br>1- велосипедчыны таптату | 1. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>2 «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>3. Җәяүлеләр өчен кисәтү юл билгеләре төшерү.<br>4. Велосипедчылар өчен индивидуаль проектлаштыру билгеләре.<br>5. «Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» федераль программа кысаларында |
| 11. | Сөембикә проспекты – Хәсән Туфан проспекты | 3 – бәрелешү<br>1- киртәгә бәрелү<br>1 – җәяүлене таптату | 1. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>2 «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>3. «Максималь тизлекне чикләү – 40 км/с» 3.24 юл билгеләре урнаштыру.<br>4. Рәшәткәле киртәләр урнаштыру.<br>5. «Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | п. 1-4 җирле бюджет<br>п. 5 – «ЮХК» ДБУ |
| 12. | Машиностроительная урамы («Лента» СҮ бинасы каршында) | 3 – бәрелешү | 1. Светофор объекты кертү. | Җирле бюджет (финанслау булганда) |
| 13. | Сөембикә проспекты – Автозавод проспекты | 3 — җәяүлене таптату | 1. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>2. «Тигезсез юл». 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>3. «Җәяүлеләр кичүе» 5.19.1 кабатлау билгеләрен диод яктырткычлы билгеләргә алмаштыру.<br>4. Җәяүлеләр өчен кисәтү юл билгеләре урнаштыру. | Җирле бюджет (финанслау булганда) |
| 14. | Мәскәү проспекты – Рәис Беляев проспекты (5/05 йорт) | 5–бәрелешү | 1. Тавыш полосалары урнаштыру.<br>2. «Тигезсез юл». 1.16 юл билгеләре урнаштыру.<br>3. «Куркыныч юл участогы» индивидуаль проектлаштыру билгеләре урнаштыру. | Җирле бюджет (финанслау булганда) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15. | Мәскәү проспекты – Автозавод проспекты | 3 – җәяүлене таптату<br>2- бәрелешү | 1. «Җәяүлеләр кичүе» 5.19.1 кабатлау билгеләре урнаштыру» - 4 данә.<br>2. «Фотовидеофиксация» 8.23 табличкасы белән «Максималь тизлекне чикләү – 40 км/с» 3.24 юл билгеләре урнаштыру<br>3. «Автоураган» фотофиксация приборлары урнаштыру (финанслау булганда). | п. 1-2 – җирле бюджет<br>п. 3 – «ЮХК» ДБУ |
| 16. | Яр Чаллы проспекты, 16а (4 нче шифаханә) | 3– бәрелешү | 1. Ремонт вакытында борылмада КТП өстәргә. | «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» федераль программа кысаларында |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова